МИНИСТЕРСТВО
ЗДРАВООХРАНЕНИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТ
СӘЛА
МІ

**ПРИКАЗ**

20.07.2017 **г. Казань** **№** _

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркем алырлык мәгълүматны, шулай ук аларны тиңләштерергә рөхсәт итүче мәгълүматларне урнаштырган «Интернет» мәгълүматый-телекоммуникацион челтәрендә сайтларның һәм (яисә) сайтлар битләренең адреслары турында белешмәләрне кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен раслау турында

2004 елның 27 июленнән № 79-ФЗ «Россия Федер
хезмәте турында» Федераль законының 20.2 статьяс
«Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хез
Республикасы законының 17.2 статьясына туры кит

ТР ССМ 2017 елның
20 июленнән №1575
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы граждannar һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркем алырлык мәгълүматны, шулай ук аларны тиңләштерергә рөхсәт итүче мәгълүматларне урнаштырган «Интернет» мәгълүматый-телекоммуникацион челтәрендә сайтларның һәм (яисә) сайтлар битләренең адреслары турында белешмәләрне кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы граждannar һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркем алырлык мәгълүматны, шулай ук аларны тиңләштерергә рөхсәт итүче мәгълүматларне урнаштырган «Интернет» мәгълүматый-телекоммуникацион челтәрендә сайтларның һәм (яисә) сайтлар битләренең адреслары турында белешмәләрне кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибе (түбәндә – Тәртип) билгели:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы граждannar (түбәндә гражданин) һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (түбәндә – граждан хезмәткәре, Министрлык) һәркем алырлык мәгълүматны, шулай ук аларны тиңләштерергә рөхсәт итүче мәгълүматларны урнаштырган «Интернет» мәгълүматый-телекоммуникацион челтәрендә сайтларның һәм (яисә) сайтлар битләренең адреслары турында белешмәләрне (түбәндә – Сайтлар турында белешмәләр, «Интернет» челтәре) тәкъдим итү кагыйдәләрен;

Сайтлар турында белешмәләрне кабул итү һәм эшкәртү тәртибен;

Сайтлар турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибен.

2. 2006 елның 27 июленнән № 149-ФЗ «Мәгълүмат, мәгълүматый технологияләр турында һәм мәгълүматны яклау турында» Федераль законы 1 бүлеге 7 статьясына туры китереп һәркем алырлык мәгълүмат астында һәркемгә билгеле белешмәләр һәм ала алырлыгы чикләнмәгән башка мәгълүмат аңлатылалар. Шуның белән бергә мәгълүматның ала алырлыгында чикләү булмавы чикләнмәгән шәхесләр даирәсенең тоткарсыз алу һәм граждан хезмәткәренең яисә гражданинның ризалыгыннан башка урнаштырылган мәгълүматны үзенең теләгәнчә сарыф иткән куллану мөмкинлеген ниятли.

3. Граждан хезмәткәренең яисә гражданинның кемлеген билгеләргә рөхсәт итүче мәгълүматлар сыйфатында түбәндәге белешмәләрнең барлыгы бергә яисә берсе чыгыш ясый ала: Фамилиясе һәм исеме, фотографиясе, хезмәт урыны.

## II. Сайтлар турында белешмәләрне кабул итү һәм эшкәртү тәртибе

4. Сайтлар турында белешмәләрне тапшыралар :

гражданин - гражданлык хезмәтенә керү елы алдында булган өч календарь елы эчендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә (түбәндә – гражданлык хезмәте) керү вакытында;

граждан хезмәткәре – ел саен хисап елы артыннан елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча, алдагы календарь елы өчен.

5. Сайтлар турында белешмәләр гражданнар һәм граждан хезмәткәрләре тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте белән билгеләнгән формасы (түбәндә – Форма) буенча тапшырылалар.

6. Һәркем алырлык мәгълүмат, әгәр ул граждан хезмәткәренең хезмәт вазыйфаларын үтәү кысаларында урнаштырылган, Формада чагылдырылырга тиеш түгел.

7. Язып тутырылган Форма граждан хезмәткәре яки гражданин белән Сайтлар турында белешмәләр эшкәртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы белән җаваплы итеп билгеләнгән (түбәндә – җаваплы шәхес) кадрлар бүлегенең хезмәткәренә тапшырыла.

8. Җаваплы шәхес Форманы тутыруның тулылыгын, «Интернет» челтәрен куллану белән анда күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеген тикшерә, шәхси имзасын куя, Форманы алу көнендә әлеге Тәртипкә Кушымта нигезендәге форма буенча белешмәләрне журналга кертә.

9. Тутырылмаган урыннары булган Форма кабул итергә тиеш түгел.

10. Гражданин белән тәкъдим ителгән Формада дөрес булмаган белешмәләрне ачыклау очрагында, кадрлар бүлеге гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләүдән баш тарту турында тоткарсыз белдерә.

11. Сайтлар турында белешмәләр җаваплы шәхес белән «Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составының ярдәм мәгълүмат системасы» дигән Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында граждан хезмәткәрләренең шәхси карточкаларына кертеләләр.

12. Граждан хезмәткәрләре һәм гражданнар белән тәкъдим ителгән Формалар биш ел дәвамында кадрлар бүлегендә сакланалар, шуннан соң Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Шәхси мәгълүматларны эшкәртү кагыйдәләре белән билгеләнгән тәртиптә юкка чыгарылырга тиеш.

## III. Сайтлар турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибе

13. Граждан хезмәткәрләре белән тәкъдим ителгән Сайтлар турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры вазыйфасын башкаручы шәхес) (түбәндә – министр) боерыгы буенча гамәлгә ашырыла.

14.Закон саклаучы органнар, башка дәүләт органныры, җирле үзидарә органнары һәм аларның урындагы шәхесләре белән;

сәяси партияләрнең даими гамәлдәге җитәкче органнары һәм законга туры китереп теркәлгән сәяси партияләр булмаучы башка гомумроссия, регионара һәм региональ иҗтимагый берләшмәләре белән;

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән;

гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чаралары белән язма төрендә тәкъдим ителгән җитәрлек булган мәгълүмат тикшерү өчен нигез була.

15. Җаваплы шәхес граждан хезмәткәрен тикшерүне уздыру турында боерык бастырып чыгарудан ике эш көне дәвамында аңа карата тикшерү башлануы турында язма рәвештә белдерә.

16. Граждан хезмәткәре белән тәкъдим ителгән Сайтлар турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү «Интернет» челтәрендә аның белән урнашкан һәркем алырлык мәгълүматне эзләү аша җаваплы шәхес белән гамәлгә ашырыла.

17. Граждан хезмәткәре тикшерү барышында язма рәвештә аңлатмалар бирергә һәм тикшерү нәтиҗәсендә өстәмә материаллар тәкъдим итәргә хокуклы.

18. Әлеге Тәртипнең 17нче пунктында күрсәтелгән аңлатмалар тикшерү материалларына теркәп куела.

19. Тикшерү материаллары һәм тикшерү барышында җыелган мәгълүмат тикшерүне уздыру турында боерык бастырып чыгарудан ун эш көненнән дә артыграк булмаган срокта министрга тәкъдим ителәләр.

20. Тикшерү нәтиҗәләре буенча 5 көнлек срокта министр карар кабул итә:

граждан хезмәткәренә юридик җаваплылык чараларын куллану өчен нигезләр булмавы турында;

граждан хезмәткәренә юридик җаваплылык чараларын куллану турында;

хокук бозу, җинаять, экстремистик эшчәнлегенә катнашканлык билгеләре булганда тикшерү материалларын дәүләт органнарына , аларның компетенциясенә яраштырып, җибәрү турында.

21. Кабул ителгән министр карары турында җаваплы шәхес, ике эш көне дәвамында, язма рәвештә аңа карата тикшерү уткәрелгән граждан хезмәткәренә хәбәр итә.

22. Министр язма ризалыгы белән Сайтлар турында белешмәләр, аңа карата тикшерү уткәрелгән граждан хезмәткәренә моның турында бер ук вакыттагы хәбәр итү белән, шәхси белешмәләр һәм дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнарын үтәп тикшерү уздырырга нигез булган мәгълүматны тәкъдим иткән закон саклаучы органнарга, сәяси партияләрнең даими гамәлдәге җитәкче органнарына һәм законга туры китереп теркәлгән сәяси партияләр булмаучы башка гомумроссия, регионара һәм региональ иҗтимагый берләшмәләренә; Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына, гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чараларына тәкъдим итә алачак.

23. Тикшерү материаллары Министрлыкның кадрлар бүлегендә ул тәмамлану көненнән өч ел дәвамында сакланалар, шуннан соң архивка тапшырылалар.

## IV. Сайтлар турында белешмәләрне күрсәтмәү өчен җаваплылык

24. Сайтлар турында белешмәләрне күрсәтмәү очрагында гражданин гражданлык хезмәтенә кабул ителә алмый, ә граждан хезмәткәре гражданлык хезмәтендә була алмый.

25. Сайтлар турында белешмәләрне граждан хезмәткәре белән күрсәтмәү гражданлык хезмәтеннән чыгаруны китергән хокукны бозу була.

ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының
20.07.2017 № 1575 боерыгы белән расланган
Тәртипкә кушымта

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтнең вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучыграждannar һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркем алырлык мәгълүматне, шулай ук аларга тиңләштерергә рөхсәт итүчемәгълүматларны урнаштырган «Интернет»мәгълүматый-телекоммуникацион челтәрендә сайтларның һәм (яисә) битләрнеңадреслары турында тәкъдим ителгән белешмәләрне исәпкә алу
ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Тәкъдим итү / форманы кабул итү датасы | Форманы тәкъдим иткән кешенең ФИО | Форманы тәкъдим иткән кешенең вазыйфасы (гражданин дәгъвалаганвазыйфа) | Форманы тәкъдим иткән кешенең имзасы (яисәпочта белән керү вакытында керү№.) | Форманы кабул иткән шәхеснең ФИО | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |